**ГЛАВА КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

**2024елның «28» марты** **2 номер**

## КАРАР

### Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 190 ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, кешенең тормыш эшчәнлеге өчен уңай шартларга, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елның 7 мартындагы 12-РС номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты һәм датасы – 2024 елның 19 апрелендә 14.00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү урыны – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: 422626, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Хәерби авылы, Горький урамы, 26А йорт.

2.3 Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне 422626, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Хәерби авылы, Горький урамы, 26А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге башкарма комитетына җиткерергә.

2.4 Чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 2024 елның 18 апреленә кадәр.

3. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм һәм «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү буенча документлар һәм схемалар Хәерби авыл җирлеге сайтында урнаштырылган .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Хәерби**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.К.Зинәтуллин**